«КАРА АЛТЫН»

Әлмәттә Нефть саммиты узды

> 2

ИСӘНМЕ, МЕГАФЕРМА!

Тагын бер чор – җәйләүле чор да үткәнебездә кала

> 2



АВЫЛ ИМАМЫ

«ВТ» укучыларының саладагы дин әһелләре турында язмалары

> 3

ТАШКА БАСЫЛГАН

Әдәбият һәм матбугат мәсьәләләре турында махсус сәхифә

> 4

ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН

1918 елның 12 мартыннан бирле чыга | ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ГОМУМТАТАР ГАЗЕТАСЫ | № 99 (28872) | Чәршәмбе | 13 июль | 2022 ел

Газета 1968 елда Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән бүләкләнде

www.vatantat.ru /vatanimtatarstan /t.me/vatantat

4604609 000131

ТАБИГАТЬ САТАШМЫЙ

Аномаль салкын, аномаль җылы һава торышы... Якын киләчәктә бу сүзләрне сагынып искә алырга гына туры килмәгәе. Метеорологлар хәзер бу сүзләр безнең авыздан бик сирәк чыгачак, дип ышандыра.

Илдар Мөхәммәтҗанов

Ник дигәндә, Россия Гидрометеорология үзәге белгечләре бу көннәрдә, соңгы утыз елда теркәлгән һава торышы нормаларын яңадан карап, төзәтмәләр керткән. Шуңа хәзер җил дә вакытында исеп, яңгыр да вакытында явачак, кыскасы.

Белгечләр үзләре климатик нормаларга үзгәреш кертүне гадәти хәл дип саный. «Еллар үткән саен һава торышы да үзгәрә, ул да бер урында гына тормый. Шуңа күрә һәр утыз ел саен климатик нормаларга төзәтмәләр кертелә. Соңгы елларда әйләнә-тирәдә барган үзгәрешләр нәкъ менә шушы вакыт аралыгында аермачык күренә дә инде», – ди алар.

Озак еллардан бирле һава торышын өйрәнүче «халык синоптигы», Балтач районының Яңгул авылында яшәүче Әмир абый Шәрәфиев бер сөйләшкәндә, соңгы елларда сынамышларның да рас килми башлавыннан зарланган иде. Бу юлы элемтәгә чыгуымда инде һава торышының акрынлап элеккеге эзенә кайтуын искәртте. «2010 елдагы корылыктан соң табигать көйгә килә алмыйча тилмерде. Сынамышлар да туры килми башлады. Хәзер акрынлап бар да кире үз хәленә кайта, сынамышлар да чагыша инде», – ди ул.

Шулай да быелгы һава торышының холкы сәеррәк дигән фикердә Әмир абый. Хәтерләсәгез, быел кышның соңгы ае җылы булды. Февраль урынына март килгән кебек иде. Мартта исә, киресенчә, салкыннар сакланды. «Апрель ике айга сузылды. Май өч кенә көн булып калды. Аның бер өлеше июньгә күчте – көннәр салкын торды. Шуңа күрә быел чын җәй август белән сентябрьгә авыша. Бу ике айда көннәр бик җылы булачак. Июльдәге хәзерге чилләнең исә санаулы көннәре генә калды. Айның икенче яртысы явым-төшемле, салкын булачак», – дип фаразлый «халык синоптигы».

Игътибар итсәгез, соңгы елларда җәй кышка карап килә башлады. Узган ел кыш җылы булды, шуның аркасында быел июньдә салкын иде. Җәйнең беренче аенда уртача һава температурасы, башка еллар белән чагыштырганда, 3–5 градуска түбәнрәк булды. Өченче ел кыш бик салкын килде, нәтиҗәдә узган җәйдә корылыктан интектек. Әмир абый июльнең икенче яртысында көннәрнең суытып җибәрүен дә быел «крещение суыклары» булмау нәтиҗәсе дип саный. Шул сәбәпле быел урып-җыю да соңрак башланачак.

– Урып-җыю башланыр алдыннан, елдагыча, бозлар явып, давыллап, һава торышы бозылып алыр әле ул. Быел явым-төшем артыгы белән ява бугай, дип әйтүчеләр дә бар. Әмма яңгыр, елдагыча, бар җирдә дә тигез яумый. Узган атнада бездә өч көн яңгыр яуды. Улым эшләгән Казан янындагы бер хуҗалыкта исә ул көннәрне бер тамчы яңгыр төшмәде. Аннары яңгырдан соң, гадәттә, көннәр суытып җибәрә иде. Быел, киресенчә, яңгыр яуганда да көннәр парлы, җылы булды. Икенче кат печәннәр шундук күтәрелеп китте. Соңгы елларда мондый җәйнең килгәне юк иде әле. Алдагы дүрт-биш елда да авыл хуҗалыгы өчен уңай һава шартлары сакланыр дип уйлыйм», – дип фаразлый Әмир абый.

Яңгыр дигәннән, соңгы арада ул, дөрестән дә, мулдан яуды. Узган ялларда республиканың күп кенә район-шәһәрләрендә давыллап ишкән яшенле яңгыр китергән зыянны санарга туры килде. Бигрәк тә Кукмара, Балтач, Арча районнарында яшәүчеләр зыян күрде ул көннәрдә. Кемнеңдер бакчасын юдырган, кемнең йортына яшен суккан, кайдадыр давыл мәктәп түбәсен алып аткан. Казан урамнары да елганы хәтерләтте ул көнне. 10 июльдә Мәскәүдә котырган давыл вакытында хәтта бер кешенең гомере үк өзелде. 12 кеше төрле дәрәҗәдәге тән җәрәхәтләре алган.

КФУ профессоры, география фәннәре докторы Юрий Переведенцев, яшенле яңгырлар әледән-әле явып торса да, бездә Мәскәүдәге кебек үк табигать казалары күзәтелмәс дип тынычландыра. «Мондый ук күңелсез хәлләр кабатланмас. Давыл, нигездә, Европа өлешенең үзәгенә бәрде. Килгән очракта да бездә андый давыллар җиңелчә генә узып китәчәк, – дип саный белгеч. – Пәнҗешәмбегә каршы төндә Татарстанда көннәр суыта башлаячак. Һава температурасы 5–6 градуска төшәчәк».

Илнең үзәк өлешендә давыл котырган көннәрдә айлык норманың яртысы күләмендә явым-төшем булган. Татарстанда исә яңгыр әле җитәрлек күләмдә яумады, дип ышандыра метеорологлар. Әйтик, июль башында Казанда нибары 5,4 мм явым-төшем күзәтелгән. Июнь аенда андый көчле яңгырлар булмады да диярлек. Июль аеның икенче яртысында явачак яңгырлар айлык норманы тутырып бетерер, дип фаразлый белгечләр. «Июльдә 67 мм явым-төшем көтелә. Бу – бик зур сан. Коеп яуган мондый яңгырлар кыска вакытлы була, әмма бар дөньяны суга күмә. Бу атнада да айлык норманың яртысы күләмендә яңгыр яварга мөмкин. Температура түбәнәячәк, әмма күп тә үтми җәйге эсселәр кабат әйләнеп кайтачак», – ди Переведенцев.

Динә ГЫЙЛАҖИЕВА

Июль ае сынамышлары

15 июльдә агачларда сары яфраклар күренсә, иртә көз һәм кышка.
16 июльдә озынборын һәм черкиләр түгәрәкләнеп очса, алдагы 7 көн коры һәм матур булыр.
17 июльдә болытлар бер буй булып сузылып ятса – җылы көннәргә.
18 июль киче көндезгә караганда җылырак булса – яңгырга.
19 июль дымлы булса, сентябрьдә юеш булыр.

50 меңнән артык шикаять

Гыйнвардан июнь аена кадәр «Халык контроле»нә 50907 шикаять алынган. Узган елның шушы ук чорындагыга караганда 13 процентка кимрәк бу. Хәзергә 34868 хәбәрдә күтәрелгән мәсьәлә хәл ителгән, 3132се буенча тиешле эш алып барыла. 10175 шикаять соңрак каралачак. Хәбәрләрнең күбесе (17682), гадәттәгечә, «Юллар» категориясенә туры килә. Икенче урында (15327) – «Төзекләндерү һәм инфраструктура». «Атамаларда хаталар» категориясе – өченче. Туган теленә битараф булмаган кешеләрдән урам исемнәрендәге, алтакталардагы язуларда төгәлсезлекләр буенча барлыгы 3,5 мең хәбәр алынган. Шунысын да әйтеп үтәргә кирәк: Татарстан «Халык контроле» дәүләт мәгълүмат системасына җибәрелгән шикаятьләр исәбенә Россия Дәүләт хезмәтләре порталындагы кире элемтә сервисы аша алынган 9526 хәбәр дә кертелгән.

Татарстанда Кеше хокуклары буенча Вәкаләтле вәкил, «Халык контроле» баш модераторы Сәрия Сабурская әйтүенчә, шикаятьләрне карап тикшерүдән баш тартучылар белән дә зур эш алып барыла. Ел башыннан районнар һәм шәһәрләр хакимиятләрендә, нигезсез дип табылган барлыгы 2637 шикаять карап тикшерүгә кире кайтарылган. Вәкаләтле вәкил аппараты хезмәткәрләре, урыннарга чыгып, 383 тикшерү үткәргән.

Яшь геологлар көч сынаша

Әлмәт районында Яшь геологларның VIII республика ачык кыр олимпиадасы башланды. Ярышлар «Солнечный» балалар сәламәтләндерү лагере базасында уза. Олимпиадада Татарстан данын 31 командадан 286 укучы яклый. Шулай ук чарада Пермь крае, Кырым, Беларусь, Казахстан һәм Үзбәкстаннан да яшь геологлар катнаша. Олимпиада 17 июльгә кадәр дәвам итәчәк.

Яшь геологлар кыр тукталышын оештыруда ярыша, минераллар, тау токымнарын өйрәнә, нефть эзли. Гидрология, радиометрия, магнитометрия, куркынычсызлык техникасы нигезләре буенча һәм башка сынауларны уза.

Күп кенә балаларның олимпиадага беренче тапкыр гына килүе түгел. Катнашучыларның күбесе киләчәктә үз язмышларын геология белән бәйли. Кыр геологик олимпиадасы үткәрелә башлаганнан бирле 300дән артык егет һәм кыз шушы һөнәрне сайлаган. Жидесе олимпиадага команда җитәкчеләре булып әйләнеп кайткан.

Акчасыз түгелбез

1 июньгә Татарстанда яшәүчеләрнең банк счетларындагы акчасы 769,4 миллиард сумга (өлешчеләрнең эскроу-счетлардагы акчасын кертеп) җиткән. Бер ел эчендә бу сумма 15,3 процентка арткан. Халык акчаны, элеккечә үк, сумнарда саклауга өстенлек бирелә. Июнь башына мондый кертем өлеше кешеләрнең банктагы барлык акчасының 88,9 процентын (684,4 млрд сум) тәшкил иткән. Бер ел эчендә үсеш – 19%. Ә менә чит ил валютасында салынган акча 8 процентка кимеп, 85 миллиард сумга калган. Россия Банкы Татарстан буенча бүлеге идарәчесе Марат Шәрифуллин әйтүенчә, акча салу буенча барлык төп шартларны килешү башында ук таблицага урнаштыруны күздә тоткан закон кабул ителгән. Анда кертем ставкасы, вакыты, күләменнән тыш, клиентларның игътибарыннан еш кына читтә калучы башка нечкәлекләр дә күрсәтеләчәк.

Оешмаларга килсәк, аларның да банклардагы акчасы күләме, 2021 елның шушы ук чорындагы белән чагыштырганда 33,8 процентка артып, 572 миллиард сумга җиткән.

Машинаны – интернет аша

Россия Дәүләт хезмәтләре порталында автомобильләрне сату-алу сервисы эшли башлаган. RT хәбәр иткәнчә, хәзер интернет аша төзелгән килешү кәгазьдә имзаланганы белән бер үк төрле әһәмияткә ия булачак. Онлайн алыш-биреш ясау өчен сатучының да, сатып алучының да яше 18дән өстәрәк булырга һәм алар Дәүләт хезмәтләре сайтында теркәлгән булырга тиеш. Алыш-биреш турында килешү «Госключ» кушымтасы ярдәмендә имзалана.

pixabay.com

Яшәеш

Чикләр кирәк куярга

Татарстанның чикләрен билгеләү дәвам итә. Ул 3403 чакрымга сузылган, 4 республика һәм 4 төбәк белән кисешә. Теркәлмәгән җирләрнең хуҗаларын эзләү дәвам итә. Удмуртия Республикасы һәм Киров өлкәсе янәшәсендәге мәйданда килеп туган каршылыклар хәл ителгәч, Татарстан чикләрен билгеләү тәмамланачак.

Бу хакта Министрлар Кабинетында узган брифингта Татарстанның җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министры Фәнил Әһлиуллин хәбәр итте.

– Әлеге эшләр федераль программа ярдәме белән беренче тапкыр уздырыла. Моның өчен бюджеттан 10 миллион сум акча бирелде, – ди министр. – Чикләрне билгеләү вакытында төрле каршылыклар килеп чыкты. Эш барышында 573 мәйданның хуҗасын ачыкларга туры килде. Чикләр билгели башлагач, Татарстанның мәйданы 139 гектарга артты. Чүпрәле районында, мәсәлән, Чувашия Республикасына караган җирләр барлыгы ачыкланды. Башкортстан Республикасында да 7 урында проблемалар белән очраштык. Шөкер, аларның барысы да хәл ителде. Төбәк җитәкчеләре үзара сөйләшеп, уртак фикергә килә алды. Хәзерге вакытта проблемалы өч мәсьәләне хәл итәсе бар.

Фәнил Әһлиуллин сүзләренә караганда, Татарстанның чикләрен билгеләү эшләре ел ахырына тәмамланырга тиеш. Хуҗасыз җирләр дәүләт милке булып теркәләчәк, ияләре булганнары да кадастр исәбенә куелыр дип планлаштырыла. Җирләрне ачыклап кына калмыйлар, республиканың бердәм картасын да булдыралар. Баксаң, республикада хуҗасы булып та теркәлмәгән җирләр күп икән. Росреестрның Татарстан буенча идарәсе җитәкчесе урынбасары Лилия Борһанова әйтүенчә, бер ел эчендә республикада 9 меңнән артык объект кадастр исәбенә куелган, 404 объект төшерелгән.

– Һәркем үз милкен рәсмиләштерсен иде. Бу, беренчедән, аларның үзләре өчен кирәк. Әйтик, күп кенә мошенниклар, ялган документлар табып, чит кеше милкен үзенеке итеп рәсмиләштереп тә куя. Җирнең чикләрен билгеләү дә мөһим. Күрше белән күрше арасында килеп чыккан низагларга шул документ нокта куя. Үз җирең булып та, аны рәсмиләштермәсәң, синеке икәнне раслатыр өчен, судка барырга кирәк, – ди белгеч.

Лилия Борһанова сүзләренчә, М12 трассасы төзелә башлагач та, җиргә бәйле кайбер каршылыклар килеп чыккан. «Кайберәүләрнең җир өчен бирелгән документлары югалырга да мөмкин. Андый очракта авыл җирлекләренә, район хакимиятенә мөрәҗәгать итәргә кирәк. Архив документлары аша да җир хуҗасын эзләп табарга була», – ди ул.

Белгечләр җирне исәпкә куяр өчен күпфункцияле үзәкләргә барырга киңәш итә. Әгәр җиргә хокук бирүче документыгыз бар икән, аны теркәгәндә дәүләт пошлинасы түләтелми.

Очрашуда «дача амнистиясе», «гараж амнистиясе» турында да сүз булды. Дача җирләрен теркәтергә теләүчеләр, әлеге җиргә 2001 елның 30 октябренә кадәр хуҗа икәнлекләрен расласалар, ул җирләрне бушлай теркәтә алалар. Шулай ук әлеге милек аларга мирас булып калган очракта да, алар «дача амнистиясе»нә өметләнә ала.

Гаражларны теркәү бераз четерекле. Аларның 1998 елның маена кадәр төзелгән булуы кирәк. Металлдан гына эшләнгән гаражларга кагылмый бу. Аларның кирпечтән төзелгән булуы шарт. Гараж җирләрен теркәтү өчен, җирле үзидарәгә барып, гариза калдырырга кирәк булачак.

Гөлгенә ШИҺАПОВА

Сүзгә-сүз

rg.ru

Антон СИЛУАНОВ, Россиянең финанс министры:

Россия Финанс министрлыгы өстенлекле чыгымнарны билгеләргә тәкъдим итте. Алар хисабына янга калган акча яңа максат һәм бурычларны тормышка ашыру өчен тотылачак. Иң беренче чиратта, чикләүләр аркасында зыян күргән кешеләр, эшмәкәрләр һәм тармакларга ярдәм итәчәкбез. Моңа кадәр читтән кертелгән технологияләрне дә үзебездә җитештерәчәкбез.

(«Ведомости» басмасындагы әңгәмәсеннән)

РОССИЯДӘ – АВТОТУРИЗМ

«Автостат» агентлыгы Россиядә яшәүчеләрнең, ерак җирләргә сәфәр кылу өчен, нинди машина моделенә өстенлек бирүләрен ачыклаган.

Автотуризм өчен иң еш сайлана торган машина модельләре:





Рәшит ФӘТХРАХМАНОВ

Дөньяда

БАЙДЕН РОССИЯГӘ КАРШЫ

Россия – күмәк Көнбатыш конфликты үзенең югары ноктасына таба хәрәкәтен дәвам итә. Санкцияләр бумерангы әлегә Көнбатышның үзенә дә бик каты суга: газга бәяләр котырып үсә, нефть тә арзан түгел. Астыртын көнбатышлылар еш кына яшерен генә үз санкцияләрен үзләре дә бозарга мәҗбүрләр. Әйтик, Бөекбритания – иң беренче булып Россия нефтенә эмбарго керткән ил – үз тыюларын үзе бозып, Россия ягулыгын сатып ала. Refinitiv – финанс базарлары һәм инфраструктура турында мәгълүматлар бирүче компания – Берләшкән Корольлекнең февраль ахырыннан башлап Россиядән 800 миллион фунт стерлинглык дизель ягулыгы сатып алуын әйтә. Австрия дәүләт резервындагы ягулык запасларын – 100 мең тонна дизель ягулыгын һәм 45 мең тонна башка нефть продуктларын сатуга чыгарды, чөнки хәл кискен.

Россия үзе дә «дошманнар» җитештергән технологик продуктларга мохтаҗ. Аларны «дус илләр» аша параллель импорт ярдәмендә китертә. Бу кыйммәткә төшә, әлбәттә. Үзара сәүдә итешеп, тыныч кына яшисе, үсәсе иде дә бит, әмма сәясәтчеләр «әбигә үч итеп, колакны өшеттем» дигән принцип буенча яшиләр.

Шулай да башында Байден Америкасы торган күмәк Көнбатыш җайлап кына санкцияләр кыршавын кыса. Россия нефтенә «түшәм бәя» кую турында актив сөйләшүләр бара. 40–60 долларлык чиктән уздырмаска телиләр. Моңарчы Мәскәү нефтьне нинди бәягә сатты? Санкцияләргә кадәр 42 доллардан. Ышанмассыз да инде: дөнья базарында «кара алтын» бәясе күпме генә булмасын, Россия аның өчен менә шул бәядән генә акча алды. Бу хакта без махсус язма әзерләрбез, Аллаһ теләсә. Санкцияләр кертелгәч кенә, «түшәм» биегәйде һәм сум курсы үсә башлады. Хәзер яңадан шул «түшәм» астына кире кайтарырга телиләр.

АКШ Россиягә «параллель импорт» аша товар озатучы илләрнең исемлеген булдырып, аларны йөгәнләргә тели. Исемлектә Әрмәнстан, Грузия, Бразилия, Казахстан, Кытай, Һиндстан, Израиль, Мексика, Никарагуа, Сербия, Сингапур, Көньяк Африка, Тайвань, Таҗикстан, Төркия, Берләшкән Гарәп Әмирлекләре, Үзбәкстан бар. Бу илләр белән Россия арасында чөй кагу максаты тормышка ашырыла. Һич югында параллель импортка юл куймасыннар дигән теләк тә көчле. Көрәш бик кискен бара. Һәм янкилар уңышка да ирешәләр. Казахстан, мәсәлән, тыелган товарларны Россиягә үткәрмәү өчен чаралар күрү юлында. Европага Россия нефте урынына казах нефтен озату турында Токаев вәгъдәсе дә тормышка ашырылыр, мөгаен. Астана хәтта «кара алтын»ны, Россияне әйләнеп, «ефәк юлы» аша озату чарасын да күрә башлады.

«Нью-Йорк Таймс» газетасы Байденның Якын Көнчыгышка визиты әзерләнүен хәбәр итә. Визитның берничә максаты бар. Гарәп илләре, нефть чыгаруны арттырып, җир маеның бәясен төшерергә тиешләр. Төп максат шулдыр, ихтимал. Россия байлары үз активларын Европадан Дубайга күчерделәр. «Хәтерсез Байден» шул активларны Берләшкән Гарәп Әмирлекләрендә туңдырып бикләтү максатын да куя.

Гарәп илләре элек-электән совет хәрби техникасын күпләп сатып алдылар. Байден гарәпләрне шул техниканы Украинага озатырга күндерү өчен дә бара. Украина армиясе совет коралы белән эш итәргә өйрәнгән, гарәпләрдән шул техниканы Киевка китерү кулай булыр, дип фикер йөртәләр Ак йортта. Байденның визиты уңышлы булса, Россия өчен проблемалар артачак. Шул рәвешле киеренкелекне үстерү дәвам итә.

Россиядә

15 ИЮЛЬ ИНТРИГАСЫ

Россиялеләрнең күпчелеге атом бомбасы шартлаудан түгел, дефициттан күбрәк куркалар икән. Сораштырулар статистикасы шуны күрсәтә. Шулай да атна башында мәгълүмат кырына чыккан бер хәбәр сәясәт белән кызыксынып яшәүчеләрне тәшвишләндерде. Сәясәт белән бер дә кызыксынмый яшәү дә мөмкин түгел, чөнки беләбез бит инде: син кызыксынмасаң, сәясәт синең белән кызыксына.

Менә шундый шартларда Дәүләт Думасының, ялга киткән депутатларны җыеп, 15 июльдә чираттан тыш утырыш үткәрәчәге турында рәсми хәбәр мәгълүмат кырында җиңелчә дулкын кузгалтты, имеш-мимешләр тарала башлады. Җитмәсә, Федерация Советының да шул көнне җыелырга ниятләве турында мәгълүмат та күренде. Ике палатаның да шулай ашыгыч рәвештә җыелуы гадәттән тыш очракларда гына була. Шуңа күрә төрле вәсвәсәләрнең шомлы фаразларга әйләнүе гаҗәп түгел. Диван аналитиклары «сугыш игълан итәләр икән, мобилизация башланачак» дигән хәбәрләр тарата һәм аларны үзләренчә «нигезли» дә башладылар. Соңгысы хәтта «диван патриотик сугышчылары»н да шомландырды. «Телевизорда «Аккош күле» балеты куячаклар икән» дигән тиле фикерләргә кадәр күренде. Рәсми даирәләр дә халык күңелендә ниләр баруын күзәтеп торалар икән. Вячеслав Володин – парламент спикеры – тынычландыргыч белдерү белән чыкты. Гадәттән тыш берни дә юк. Илдәге вазгыятькә бәйле рәвештә соңгы атналарда Думага закон проектлары бик күп керә. Күбесе хөкүмәт тарафыннан эшләнгән ул проектларны укып, канунга әйләндерүне кичектерергә ярамый. 4 июльдән башлап 42 закон проекты кергән, ике атна эчендә 86 инициатива җыелган. «Беренче чиратта сүз икътисадка ярдәм итү чаралары һәм шулай ук гражданнарны һәм хәрби хезмәткәрләрне социаль яклау турында бара», – диде Володин. Министрлар Кабинеты керткән бер проект, мәсәлән, туендыручысын югалткан балаларга пенсияне гариза язып тормыйча билгеләү турында. Гамәлгә керәчәк законнарның диапазоны бик киң, әмма арада тәшвишләндерерлек берни дә күренми кебек. Федерация Советының да ашыгыч җыелуы кануннарны гамәлгә кертүне ашыктыру өчен генә икән. Утырышның анысы турында әле карар кабул ителеп тә бетмәгән. Рәсми позиция менә шундый. Калганын вакыты җиткәч белербез, Аллаһ теләсә. 15 июльгә күп калмады бит.

ПРЕЗИДЕНТ КӨНДӘЛЕГЕ

ҮЗЕҢНӘН ЯХШЫРАК БУЛСЫН

Әлмәттә яшәүче 11 нче сыйныф укучысы Альбертка хәзер уку белән беррәттән, район башлыгы янына эшкә дә йөрергә туры киләчәк. Нефть саммиты вакытында республика җитәкчелеген таң калдырган егетне Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов Әлмәт районы башлыгы Тимур Нагумановның экология мәсьәләләре буенча киңәшчесе итеп билгеләргә кушкан.

«Рөстәм Миңнеханов белән очрашу барышында Альберт безгә бик күп сораулар бирде. Шәхсән миңа да бик күп гозерләре булды. Шуннан Рөстәм Нургали улы аны экология мәсьәләләре буенча штаттан тыш киңәшчем итеп билгеләргә кушты. Аның белән бу хакта сөйләштек инде. Ул безгә шәһәрдә, мәктәпләрдә экологияне популярлаштыру буенча киңәш-тәкъдимнәрен җиткерәчәк. Аның белән һичшиксез эшләячәкбез», – ди район башлыгы.

Экология димәктән, Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов фикеренчә, республикада бу өлкәдәге барлык тәкъдимнәргә, бигрәк тә яшьләр проектларына зур игътибар бирелә. «Татнефть илчеләре» проектының икенче турында җиңүчеләр белән очрашуда шул фикерне җиткерде ул. Бишенче, алтынчы сыйныф укучылары арасында тормышка ашырылучы әлеге программа балаларда әйләнә-тирәлеккә карата сакчыл караш тәрбияләүне максат итә. Бүген әлеге проектта 1 меңнән артык мәктәп катнаша.

– Без табигать белән якын мөнәсәбәттә булырга тиеш. Чиста һава, су, җир – иң мөһим әйберләр. Экология мәсьәләләре һәрчак өстен булачак. Табигатьне киләчәк буыннар өчен дә саклап калырга кирәк, – диде Рөстәм Миңнеханов.

Бу урында Рөстәм Миңнеханов әтисенең урманчы булуын, балаларында кечкенәдән табигатькә сакчыл караш тәрбияләвен дә искә алды. «Мәктәптә укыганда безне урман утыртырга, чистартырга җибәрәләр иде. Мин бүген дә өмәләрдә бик теләп катнашам», – диде Татарстан Президенты.

Оста җитәкче булу өчен исә укытучыңның яхшы булуы кирәк. Әлмәттә узган Халыкара нефть-газ яшьләр форумында исә Рөстәм Миңнеханов әнә шул фикерне җиткерде. Республика җитәкчесе Татарстанның беренче Президенты Минтимер Шәймиев белән эшләгәндә бик күп әйбергә өйрәнүен искәртте. Рөстәм Миңнеханов фикеренчә, оста җитәкче булу өчен, яшь белгечләргә басым ясап, ышанычлы команда да тупларга кирәк.

Форумга катнашу өчен Ташкенттан ук килгән яшьләр Президенттан Татарстан белән Үзбәкстан арасында хезмәттәшлекнең нинди юллар ярдәмендә үсүен дә сорашты. «Үзбәкстан – безнең стратегик хезмәттәшебез. Без икътисади һәм гуманитар хезмәттәшлекне актив рәвештә үстерәбез. «Татнефть», «КамАЗ» кебек оешмаларыбыз Үзбәкстанда да уңышлы гына эшләп килә. Бу илдә бүген бик күп татарлар да яши. Элемтәләребез алга таба да ныгыр дип өметләнәбез», – диде Рөстәм Миңнеханов. Форумда катнашучылар биотехнология, биоэнергетика мәсьәләләре турында да фикер алышты.

НЕФТЬЧЕЛӘР АЛДА

Егерменчесе. Әлмәтнең «Юность» лагеренда Татарстан Президенты катнашында республика нефть компанияләре җитәкчелегенең еллык саммиты узды. Рөстәм Миңнеханов анда бүгенге катлаулы шартларда Россиягә дөнья күләмендә энергетика базарында үзенең тоткан урынын саклап калуның мөһимлеген белдерде.

tatarstan.ru

Саммит үзенең 20 еллык тарихында абруйлы чараларның берсенә әйләнде. Анда нефть тармагын үстерүнең көн кадагына суга торган мәсьәләләре карала, икътисади үсешнең яңа нокталары табыла, төп мәсьәләләр буенча хакимият белән бизнесның уртак фикере булдырыла.

Чит ил шылтыравыгы кирәкми

Чара алдыннан Татарстан Президенты «Татнефть»нең, башка нефть компанияләренең казанышларын чагылдырган күргәзмәне карады. Экскурсияне компания башлыгы Наил Мәганов үткәрде. Аның барышында иң элек импортка бәйлелек турында сүз чыкты. «Ни өчен барысы да импортка бәйсезлекнең мөһимлеге турында сөйли? Нефть бетәр, дип куркалар чөнки. Әмма ул бетмәячәк. Нефтьнең 58 проценты аяк астында ята әле», – диде Мәганов. Аның әйтүенчә, «Татнефть» асылда Россия технологияләрен куллана. Президент, үз чиратында, компаниянең күп кенә патентларны теркәткәнлеген искәртте. «Безгә беркем дә – Shell да, Chevron да технологияләр бирмәде. Институтның эш җимешләре болар. Без скважиналарны гадәти бораулау җайланмалары белән борауладык. Барлык мәсьәләләр дә хәл ителгән», – диде Рөстәм Миңнеханов. Наил Мәганов хәзер компаниянең үзебездә җитештерелгән җайланмалардан файдалануын әйтте. Аның әйтүенчә, импортны алыштыру өчен әллә кайлардан әллә нәрсәләр эзләргә кирәкми. Алар барысы да бар, кулланырга гына кирәк. «Чит ил шылтыравыклары да, тимере дә кирәкми. Үзебезнеккеннән файдаланыйк. Шулай икән, илебезнең энергетик иминлеген тәэмин итәчәкбез», – диде Мәганов.

Быел компания җир асты катламнарын эшкәртү өчен үз программасын булдырган. Шулай ук нефть чыгаруда су чыгымы исәбен алып баруның заманча системасы файдалануга кертелгән. Компания башлыгы шулай ук ТАНЕКО нефть эшкәртү заводында да үзебездә җитештерелгән җиһазлар кулланылуын искәртте.

Максат – нефть мәктәбе булдыру

Саммитта иң элек Татарстан Президенты сүз алды. Ул Көнбатыш илләре гамәлләренең Россиянең дөньяда энергетика базарында алдынгылыкта баруын туктатуга юнәлдерелгәнлеген әйтте. Моңа каршы тору өчен, углеводородлар чыгару һәм эшкәртүдә үзебезнең технологияләрне үстерергә кирәк. «Бүгенге этапта без Россиянең дөньякүләм энергетика базарында тоткан урынын сакларга тиешбез. Илебезнең энергия чыганаклары белән тәэмин итүче ышанычлы партнер булып торуы кемнәргәдер ошамый. Бу базарда безне эткәләү, технологияләргә юлны ябу омтылышларын күрәбез. Бәхеткә, күп кенә партнерларыбыз үзара мөнәсәбәтләрне саклап калды, бу бик мөһим. Икенчедән, технологияләребез, институтларыбыз бар. Бүген без Татарстан нефтьчеләре башкаласында. Бирედә дөньякүләм дәрәҗәдә мәгариф һәм фәнни-тикшеренү үзәге булдыру буенча бик җитди эш алып барыла. Безнең бурыч – илнең тоткан урынын саклап калу», – дип басым ясап әйтте Рөстәм Миңнеханов.

Президент фикеренчә, Татарстанга углеводородлар чималын чыгару һәм эшкәртү өлкәсендә көчле инженерлык мәктәбе кирәк. Көнбатыш санкцияләре һәм нефть запасы кимү шартларында аеруча мөһим бу. «Алдымда шундый максат күрәм: Әлмәттә иң яхшы нефть мәктәбе булырга тиеш. «Татнефть» ярдәмендә булдырыла да инде ул. Аннан башка алга таба үсеш юк. Татарстанда нефть запасы 10 миллиард тонна күләмендә дип бәяләнә, әмма инде башка төрле запас бу. Суы 90 процентка җитә, нефть күләме 3–4 тоннадан артмаска мөмкин. Заманча технологияләр кирәк, һәм без аларны эшли алабыз. Чиктән тыш ябышкак нефть чыгару тәҗрибәсе моны күрсәтте инде. Без Россия технологияләре нигезендә 3,6 миллион тонна чиктән тыш ябышкак нефть чыгарабыз. «Татнефть»нең фәнни ачышларга 250 патенты бар. Барлык җиһазлары да Россиядә җитештерелгән. Бик зур казаныш бу», – дип билгеләп үтте Рөстәм Миңнеханов.

Шул ук вакытта ул республикада алдынгы һәр инженерлык мәктәбенең аерым бер юнәлешне үстерәчәген әйтте. Мисалга, КФУ КамАЗ белән – машина төзелеше, КНИТУ «СИБУР» белән химия сәнәгате тармаклары буенча эш алып барачак, ә Иннополис университеты IT-белгечләр әзерләү буенча мәктәп булдырачак.

Чарада Дәүләт Думасының Икътисади сәясәт комитеты рәисе Максим Топилин, «Татнефть» генераль директоры Наил Мәганов, министрлыклар һәм ведомстволар вәкилләре, нефть төбәге районнары һәм шәһәрләре башлыклары катнашты.

Бу юлы да саммит Халыкара нефть-газ яшьләр форумы белән бер мәйданчыкта узды. Монысы биотехнологияләргә багышланды. Анда катнашучылар биоэнергетика, биоягулык, биопластик һәм биочимал җитештерү буенча фикер алышты.

Нәтиҗә

Берәү дә читтә калмый

Татарстан депутатлары 2019 елда халыктан сорау-наказлар җыя башлаган иде. Бу эш әле дә дәвам итә. Пандемия вакытында интернет аша күрешсәләр, хәзер инде халык белән күзгә-күз карап сөйләшергә дә мөмкин. Бу хакта «Бердәм Россия» фракциясенең ярты елда эшләгән эшләренә йомгак ясаганда Дәүләт Советы Рәисе урынбасары, «Бердәм Россия» фракциясе җитәкчесе Юрий Камалтынов сөйләде.

– Соңгы алты айда фракция депутатлары законнар буенча бик актив эшләде. Ярты ел эчендә парламент утырышлары көн тәртибенә 49 закон проекты кергән булса, шуның 31ен «Бердәм Россия» депутатлары тәкъдим итте, – диде Юрий Камалтынов. – Безнең депутатлар тәкъдим иткән өстәмәләр бакчачылык, эчәргә яраклы су, торак мәсьәләләренә бәйле. Шулай ук мәктәпләрдә куркынычсызлыкны кайгырту турында да тәкъдим булды. Татарстан депутатлары, ана капиталын фатир алганда беренчел кертем итүне сорап, Дәүләт Советы Рәисе Фәрит Мөхәммәтшинга мөрәҗәгать иткән иде. Ул безне хуплап, бу тәкъдимне Хөкүмәт Рәисе Михаил Мишустинга җиткерде. 1 июльдән «Ана капиталы турында» Законга үзгәреш кертелде. Хәзер Татарстанда 4 меңнән артык гаилә торак шартларын яхшырта алачак.

Юрий Камалтынов «Мәрхәмәт» хатын-кыз депутатлар оешмасы эшчәнлегенә дә бәя бирде. «Алар Татарстанда гына түгел, Идел буе округын берләштереп, уртак проблемаларны хәл итәләр. Бик тә четерекле сорауларны күтәреп, закон проектларына үзгәрешләр кертәләр», – диде ул.

Очрашуда халыктан килгән наказлар турында да сүз булды. Быелның 6 аенда гына депутатлар 1600 кешене кабул иткән, алардан 3 меңгә якын мөрәҗәгать килгән. Пандемия чорында башланган «Мой депутат» системасы да эшләвен дәвам итә. Халыктан килгән тәкъдим-үтенечләрнең барысын да диярлек хәл итәргә тырышалар.

– Үземә дә сораулар күп килә. Яшел Үзән районы өчен җавап бирәм мин. Башта сорауны кабул итеп алам, аннары аны чишү юлларын эзли башлыйм. Район башлыгы, җирле үзидарә рәисе белән элемтәгә керәм. Проблеманы ачыклый башлыйбыз. Кайберләрен 1–2 ай эчендә хәл итеп була. Әгәр булдыра алмаганнары бар икән, мөрәҗәгать иткән кешенең үзе белән элемтәгә чыгып сөйләшәбез. Берәү дә игътибарсыз калмый. Авыл җирендә яшәүчеләрне күбрәк су һәм юллар проблемасы борчый, – ди ул. – Түбәдән су ага, бию коллективына костюм кирәк, диючеләр дә бар. Әлбәттә, аларны да тыңлыйбыз һәм уңай хәл итәргә тырышабыз.

Юрий Камалтынов Дәүләт Думасына Татарстаннан киткән депутатлар эшчәнлеге турында да сөйләде. Аларның республиканы онытмауларын, һәркайсы белән элемтәдә торуларын әйтте.

Гөлгенә ШИҺАПОВА

САУ БУЛ, ҖӘЙЛӘҮ!

Авыл сулышы

«Җәйләүләрдә тугай, тугайларда тургай» дигән җырны күпләр хәтерлидер. Безнең заманда радиодан иң күп яңгыраган җырларның берсе иде ул. Бүгенге эстрадада инде ретро җырларга керә. Хәер, җыры гына түгел, җәйләве дә үткән заманда калып бара.

Балтач районында, мәсәлән, соңгы ун-унбиш (бәлки аннан да күбрәктер) елда нибары «Сосна» хуҗалыгы гына малларын җәйге чорга җәйләүгә күчерә иде. Җәйләү дигәч тә, элекке кебек ялан болынлыкта, көндезләрен көтүдә йөрүче сыерлар, көнгә ике мәртәбә кул белән ике дистәләп сыер савып, чиләк белән сөт ташучы, аннан бидоннар төяүче сыер савучылар турында сүз дә була алмый. Ул чакта җәйләү чоры терлекчеләр өчен үзе бер сынау була, көннәре шунда үтә дисәң дә, арттыру булмас. Шуңа күрә анда эшләүдә әллә ни романтика күренми. Өстәвенә инде чагыштырып карарга мөмкинлекләре дә була: фермаларга саву аппаратлары, сөтүткәргечләр кертелгән, кул эшләре кимегән була. Ә монда – киресенчә… Җәйләүләрнең бер-бер артлы ябыла баруына, бәлки, шушы фактор да йогынты ясагандыр.

Район газетасында эшли башлаган елларда, хәтерлим әле: авыл хуҗалыгы бүлегендә эшләүчеләр май башында инде «Малларны җәйләүгә күчерергә вакыт, кырдан яшел азык чабып кайтартырга соңгы каласыз» дигән язмалар бастыра иде. Ә көзгә таба, август ахырларында абзарларның терлекләрне кабул итәргә әзерлеген тикшереп, рейдлар үткәрелә, сентябрь урталарына җәйләүдән кайтып җитмәгән сыерлар өчен хуҗалык җитәкчеләре, белгечләре тәнкыйть утына тотыла иде. Чорына күрә мөһим булган боларның барысы да. Кышлатудан арып чыккан терлекләрнең, яшел масса, яшел үлән ашый башлагач, сөтләре арта, җәй мул сөт чоры дип йөртелә иде шул. Хәзер генә ул ел әйләнәсе бертөрле азык ашатыла башлагач, ел фасылларының йогынтысы, аермасы мөһим түгел.

– Быелга кадәр бөтен терлекләрне җәйләүгә күчерә идек, без аның бер минусын да күрмәдек, – ди «Сосна» хуҗалыгы җитәкчесе Фирдәвес Ситдыйков, ни өчен моңа кадәр җәйләүдән баш тартмадыгыз, дигән соравыма җавап итеп. – Маллар көтүгә йөрмәде, ике зур кардабыз бар иде, берсендә – сыерлар, берсендә бозаулар торды. Шактый еллар без дә ел әйләнәсе бертөрле азык ашатырга тырышабыз, шуңа күрә җәйләүгә дә ризык ташып ашатылды. Элекке абзарларда әле сыерлар бәйдә асрала иде, җәйләүдә – кардада алар иркенгә чыга. Кояш, җылы, якты. Яңгырлар озакка китсә генә борчыла башлыйсың… Сыер саву өчен махсус түбәле урын ясалган. Анда терлекчеләр өчен бөтен уңайлыгы да бар: саву аппаратлары, үткәргечләр… – сөт күтәреп йөрисе түгел. Әле терлек асларын да җыештырасы юк. Сыер савучыларга бу чорда эшләр җиңеләя, эш сәгатьләре дә кыскара. Шуңа күрә беркем дә авырсынмады. Автобус белән йөртәбез, капка төпләренә кайтарып куябыз дигәндәй… Саф һавада эшлисе. Әйтәм бит, терлекчеләр өчен дә, маллар өчен дә гади абзарлар белән чагыштырганда җәйләүнең плюслары шактый иде. Өстәвенә абзарлар май башыннан сентябрь урталарына кадәр җилләп, ял итеп тора. Ремонтларга, буярга-агартырга, чистартырга, дезинфекцияләргә бик уңайлы. Маллар да торакларга ничектер ял итеп, көч туплап кайта…

– Соңгы елларда сездә дә мегаферма төзелде. Быел малларны җәйләүгә күчерә алдыгызмы соң?



«ВТ» архивыннан

– Мегаферманың бер өлешенә 2021 елда 500 сыер малы керде, әйбәт кенә эшләп киттек. Күп еллар урталыкта йөргән идек, хәзер сөт җитештерү буенча беренче бишлектә. Бу көзгә тагын 350 сыерга исәпләнгән өлешенә сыерлар кертеләчәк. Шуңа күрә быел җәйләүдә 300 тирәсе сыер гына йөри. Мегафермага кертелгән терлекләргә җәйләүнең кирәге юк инде, алар болай да иректә, бәйсез асрала бит. Шуңа күрә быел бездә дә җәйләүнең соңгы елы булыр инде, дибез, чөнки икенче елга мегаферманың тагын 350 сыерлык өлешен дә файдалана башларга дигән ният бар. Бөтенесе 1200 сыерга исәпләнгән иде ул. Өч этапта төзеп бетерергә исәп.

Димәк, тагын бер чор – җәйләүле чор да үткәнебездә кала. Хәер, аңа карап моңсуланырга кирәкмидер. Ни дисәң дә, тормыш алга бара. Начарга түгел, яхшыга бару билгесе дип кабул итәргә кирәк. Заманчага үзгәрәбез ләбаса.

Гөлсинә ХӘБИБУЛЛИНА

ЗИРЕКЛЕНЕҢ ӘДӘП САКЧЫСЫ

Офыкка сүрән нурларын җәелдереп, салмак кына таң атып килә. Фәрештәләр канатларын җәйгән вакытта йокыңны бүлеп, тәһарәт аласың, иртәнге намазыңны укыйсың да үзеңне сафланып киткәндәй, бетмәс-төкәнмәс рәхәтлек белән чолгап аласың.

Сак кына Коръән китабымны алып ачам. Анда мондый сүзләр язылган: «Сөмбел, Коръән сердәшчең дә, тугры дустың да, юл күрсәтүчең дә булсын, 2000 ел».

Бу Коръәнне миңа сигез яшемдә авылыбызда бик күркәм дини кичә үткәргәндә, хәзрәтебез Ильяс абый Сөләйманов бүләк иткән иде. Коръән укырга өйрәнеп, беренче тапкыр зур сәхнәдә (авыл клубы минем өчен бик зур иде) «Галәкъ» сүрәсен яттан укып, аңа да бик тырышып әзерләнеп чыгыш ясаган идем.

Ул вакытта Ильяс абый тарафыннан нинди олы бүләккә лаек булганымны әле аңлап та җиткермәгән булганмындыр. Соңрак, тормышның төрле сынауларын узган чакта, көтеп алынган ике баламны югалткач, якын кешеләрем авырганда, каенана-каенатам бер-бер артлы якты дөньядан китеп барганда, төшенкелеккә бирелмәс, яшәү тәмен югалтмас өчен, нәкъ менә шушы Коръән китабы минем тугры сердәшемә әверелде. Нәкъ менә Ильяс абыйның сөйләгән вәгазьләре, үгет-нәсыйхәтләре, киңәшләре, нинди генә авырлыкларга юлыксам да, сыгылмас өчен зур этәргеч, рухи ярдәмче булды.

Ильяс абый Сөләйманов безнең Яңа Чишмә районы Зирекле авылына 1996 елның гыйнвар аенда вакытлыча, бер айга рамазан аен үткәрергә дип кенә килә. Авылда, мәктәптә тәртипсезлек арткач, хәтта кызлар да тәмәке тарта, эчә башлагач, мәктәп директоры Мәймүнә апа Хафиз кызы мәчеткә хат язып сала. Чистай шәһәренең икенче мәхәлләсеннән мәчет рәисе Салих абый Ильяс абыйны авылга алып килә.

«Зирекле күренә башлауга ук, Ильяс хәзрәт, син инде моннан китәргә уйлама, монда төпләнеп-өйләнеп кал дип, хәердогалар кылган иде, – дип искә ала ул үзе. – Дүртәр сәгать мәктәптә дәресләр алып бардым, тәравих намазы укыттым, балаларга мәчеттә дә дәрес бирдем. Китәр вакытым җиткәндә, балалар сырып алды. Абый, китмәгез инде, дип сорагач, күңелләрем күтәрелеп китте. Шулай итеп калырга булдым. Авылның аксакал картлары да монда калырга кыстый иделәр, ризалаштым».

Салих абыйның сүзләре дә килешкән, күрәсең, бер айга килгән Ильяс хәзрәт инде 26 ел буе авылыбызның тәртибен, әдәбен саклап тора.

Тәртип дигәннән, балалар, дөрестән дә, әхлак-тәртип ягыннан башка авыллар белән чагыштырганда бер дәрәҗә югарырак дип әйтер идем. Әле үзем мәктәптә укыганда, төрле ярыш-бәйгеләргә күрше авылларга барганда да анда тәмәке тартучы яисә сыра эчүче мәктәп яшендәге (!) укучыларны күреп, сәерсенеп кайта идек, чөнки безнең мәктәптә андый укучылар булмады.

Гомумән, Ильяс абыйның авыл халкының дини белемен арттыруда өлеше әйтеп бетергесез. Ярар, сабыйлар тиз өйрәнә, тиз ятлый диярсез. Әле бит 60–70 яшьлек әби-бабайларны да Коръән серләренә төшендереп, Коръәнне гарәп телендә матур, аһәңле итеп укырга өйрәтүче ул. Совет чоры тәрбиясендә үскән кешеләр өчен бу да – горурланып сөйләрлек эш бит!

Пәйгамбәребез Мөхәммәд с.г.в.: «Белемне арттырып торыгыз», – дигән. Ильяс абый үзе югары белемле (Кабан арты мәдрәсәсен, Россия ислам институтын тәмамлаган), һаман саен гыйлем алуда. «Китаплар укып, Коръән һәм сөннәт чишмәсеннән белемемне арттырып торам», – ди. Үзе дә мәчеттә дәресләр уздыра. 30–40 ир-ат, 30–40 хатын-кыз Коръән тәфсире, 40 хәдис дәресләренә йөриләр. 40лап бала Коръән укырга, намаз, дин нигезләренә өйрәнәләр.

Мәчет янында әле берничә ел элек кенә яңа бина өлгерттеләр. Бу Ураза аенда ифтар мәҗлесләре өчен. Көн саен мәчет яны гөрләп тора. Мәктәп укучылары табын әзерләүдә булышалар, монысы – хезмәт тәрбиясе. Кайбер көннәрдә авыз ачарга килүчеләр саны хәтта 100гә дә җитә. Монда мөселман кардәшләрнең артуын, бердәмлеген күреп, күңел күтәрелә, туганлык, дуслык җепләре ныгый. Мәчеткә тартылучыларның артуы да халыкның, милләтнең әхлакый яктан үсүен күрсәтә бит.

Үзе үрнәк гаилә башлыгы буларак (тормыш иптәше Гөлшат апа белән өч бала үстерәләр), без – укучыларының да, гомумән, яшьләрнең, гаиләле, тәртипле булулары өчен җан атып йөри. Никах мәҗлесләрен оста иттереп, эзлекле вәгазьләр белән алып бара. Коръән ашларын һәркемгә аңлаешлы булган вәгазьләр сөйләп уздыра. Хәтта башка авыллардан да хәзрәтегезне яраттык, аның сөйләгәнен тыңлыйсы килә дип, кунакка махсус килүчеләр дә бар.

Хәзрәтебез шәкертләре, мөселман яшьләре арасында оештырылган спартакиадаларда да актив катнашып, призлы урыннан яулап кайталар. Волейбол, кул көрәштерү, гер күтәрү буенча күп тапкыр җиңү яулады алар. Башка авыл-шәһәрләрдә Коръән уку ярышларында да мәктәп балалары алдынгы урыннарны алып килә.

Авылыбызга килгәндә, Ильяс абыйга 22 яшь булган. Максаты халыкны динле-тәрбияле итү булса, бүген дә шундый максатлар белән янып-көеп йөри ул. Алдагы көннәрдә дә Ильяс хәзрәтебезгә уңышлар телибез. Авылыбызның шундый намуслы, тәрбияле, гыйлемле имамы булганга, без бик шат һәм бәхетле.

Сөмбел САФИНА

ВТ
922
2022
1100 Болгар
Идел буе Болгар дәүләтендә
Ислам динен кабул итүнең 1100 еллыгы

БЕЗНЕҢ АВЫЛ ИМАМЫ

Игелекле Фоат хәзрәт

Сүзем – ачык йөзле, тыйнак, йомшак күңелле, игелекле туганым, авылдашым, авылыбызның түбән оч «Ихлас» мәчетенең имамы Фоат хәзрәт турында.

«Мин дини рухта тәрбияләндем. Һәр көнебез «Бисмилләһир-рахмәнир-рахим» дип башлана һәм тәмамлана иде. Ерак барасы да түгел, каршыбызда гына мәчет. Шөкер, безнең буын дога ишетүдән мәхрүм булып үсмәде. Чөнки намазын укыган, уразасын тоткан әби-бабайларыбыз белгән гыйлемнәрен өйрәтергә, гыйбадәтләргә күндерергә тырыштылар. Баланы кызыктыра, кызыксындыра белә иде алар. Бабамның миңа кайбер догаларны ятлатканын хәтерлим», – дип, үз сүзен башлап җибәрде ул.

Фоат хәзрәт әйтүенчә, Галәветдин бабасы да бик дини булган. Бик күп еллар тегермәндә эшләгән, бөртек тулы икешәр капчыкны ике иңенә салып ташый торган булган, шунлыктан күзләренә авырлык килеп, күрми торганга әйләнгән. Сукыр булса да, өйдән мәчеткә бау сузып, шуңа тотынып, намазга йөри торган булган (мәчет өйләренең каршысында урнашкан).

Бервакыт НКВДчылар мәчет манарасын кисәргә килә, Галәветдин бабай, аларга үзенең олы малын биреп, манараны кистертми кала.

Ул Азнакай районы Уразай авылында Фәрдетдин абый һәм Мәргубә апа гаиләсендә сигезенче бала булып дөньяга килә. Яшьлегендә, тиешле белемнәрен алгач, Азнакай сәнгать остаханәсенә рәссам булып эшкә урнаша. 1988 елдан алып 2016 елга кадәр ул «Хәтер» ширкәтендә рәссам булып эшли, ягъни кабер ташлары ясый.

Элек-электән, әби-бабай йогынтысында үскән бала башкалардан аерылып тора ул, дигәнне ишеткәнем бар. Алар рәхимлерәк, шәфкатьлерәк димме, әмма болай әйтү генә дә аз. Аларның күңел дөньясы да башкача, яктырак бугай. Тормышта хәйлә-мәкер белән түгел, ихласлык, тәкъвалык белән алдыралар. Балачагыннан ук канына сеңгән тәкъвалык, андыйларны шәхси тормышның ыгы-зыгыларыннан арындырып, карашын һәм уйларын кыйблабыз тарафына юнәлтергә һәм савап гамәлләр кылырга өнди.

Аз гына тарих битләренә күз салыйк әле. Безнең авылда мәчет 1918 елда төзелә. 1978 елның 12 июлендә давыл вакытында мәчет җимерелә. Шактый вакыттан соң нәкъ шушы урында мәчет салырга ниятлиләр. Аңа беренче нигез ташы 2005 елның 3 июнендә салына. Ә 2007 елның 8 июнендә «Ихлас» дип аталган мәчет бинасы калкып чыга. Шушы бинаны салдыруда ул вакыттагы хуҗалык җитәкчесе Ринат Мөхәммәдьяровның да өлеше зурдан хисаплана. Ә барлык эшләрне оештырып, башыннан ахырына кадәр янып-көеп йөрүче – Фоат хәзрәт Галәүов була. «Ул архитектор, инженер, прораб, бригадир да булды. Хәтта үзенең юбилеена бирелгән акчаны да мәчеткә салды», – диләр аның турында...

Мәчетебездә инде ничә еллар рәттән ул дин белемен дә өйрәтә. Шулай ук мәчетебездә дини бәйрәмнәрне оештыруда, үткәрүдә Фоат хәзрәтебезнең роле бик зур.

Ул – авылның җәмәгать эшләрендә иң актив катнашучы да. Яз көне зиратларыбызны чистартуда, мәчетләребезне һәм чишмәләребезне тәртиптә тотуда һәм төзекләндерүдә, ел саен Сабан туе мәйданының трибуна өлешен милли бизәкләр белән буяу, печәнен чабуда катнаша, вафат булган авылдашларыбызны соңгы юлга озату, Коръән мәҗлесләрендә кешеләрне вәгазьләү, балаларга исем кушу, яшьләргә никах уку кебек йолаларны башкара. Авыл китапханәсе оештырган чараларда да Фоат хәзрәт бик актив. Үзенең үгет-нәсыйхәтләрен үтемле итеп һәрберебезгә җиткерергә тырыша. Ә иң мөһиме: ул – һәрвакыт мәчетебездә азан яңгыратучы. «Илаһыбыз каршына басарга беркайчан да соң түгел. Бары тик аңа ихлас инану, аң-зиһенебезне ачып, тугры юлына күндергәне өчен рәхмәтле булу кирәк. Әби-бабаларыбыз, әти-әниләребез дога белән тормышка аяк басканнар, гаилә корганнар, безне тудырганнар. Безне – балаларын да дога белән үстергәннәр. Дөнья ул – ахирәт басуы: ни чәчсәң, шуны урырсың, диелә хәдистә. Бездән соң киләчәк буыннар да бу басуны дога белән сугарсыннар иде», – ди ул.

Гөлназ ГЫЙЗЗӘТУЛЛИНА.
Азнакай районы Уразай авылы



Илдар Мөхәммәтҗанов

Безнең Искәндәр

Чал Иделнең горур Кама елгасы белән кушылган урыныннан ерак түгел урнашкан, табигатенең матурлыгы, кешеләренең уңганлыгы белән дан казанган Бәрлегуҗа авылы бар. Авыл халкы элек-электән бер-берсенә ярдәм итеп, күршеләренең кадерен белеп яшәгән. Көн саен хәл белергә керүче Мәрьям апаны мин бик сагынып искә алам. Эш сөюче күршебез тиз генә килеп керер иде дә, тегесен-монысын сөйләшкәч, «Безнең Искәндәр», – дип, киявен мактаганнан соң чыгып та китәр иде. Яңа гына килен булып төшкәнлектән, мин кешеләрне әле начар беләм, Мәрьям апаны да бераз арттыра дип уйлый идем. Тиздән миңа Искәндәр абый белән танышырга насыйп булды.

Апас районының Борындык авылында, Хәлиулла абый белән Миңнегаян апалар гаиләсендә бишенче бала булып дөньяга килә ул. Җиде баланы да эш сөючән, туган җанлы итеп тәрбияли әти-әнисе. Барлык яшьтәшләре кебек үк, Искәндәр Хәлиулла улы да урта мәктәпне тәмамлый, армия сафларында хезмәт итә. «Егет кешегә җитмеш төрле һөнәр дә аз» дигән халык мәкале аңа бик тә туры килә. Гомер барышында ул бик күп төрле һөнәрләр үзләштерә.

Әти-әнисенә, туганнарына ярдәм итү өчен бик еш туган авылына кайтып йөри Искәндәр абый. Тирә-якны мамыктай ак кар каплап, кешеләр Яңа елны каршыларга йөргән көннәрнең берсендә иптәш кызына кунакка кайткан Кама Тамагы гүзәле Илсөяр Харис кызы белән таныша. Табигать хәтфәдәй яшел юрганын ябынып, чәчәкләргә төренгән җәй аенда ике яшь йөрәк кавыша. Шул көннән башлап Искәндәр Хәлиулла улы тормыш иптәшенең әти-әнисе, туганнары өчен дә ныклы терәккә әйләнә. Алар Илсөяр апа белән иңне иңгә куеп эшләп, Казан шәһәрендә фатир алалар. Илдә булган вакыйгалар бу гаиләгә дә кагылмый калмый – Чернобыль атом электр станциясендә авария булгач, Искәндәр абыйга военкомат кушуы буенча, гаиләсен калдырып, зыян күргән җирләрне радиациядән чистарту эшләренә китәргә туры килә. Андагы хәлләр турында бер дә искә төшерергә яратмый ул. Сәламәтлеге еллар узу белән какшый барса да, зарланмый, хәрәкәттә – бәрәкәт, ди. Бер дә тик тормый.



Илсөяр апаның әнисе олыгайгач, шәһәрдәге тормышны ташлап, бу тату гаилә Бәрлегуҗа авылына кайтып төпләнә. Лаеклы ялга чыккан алтын куллы Искәндәр абый эшне нигезне төзекләндерүдән башлап җибәрә. Мәрьям апаны соңгы юлга озаткач та, авылны ташлап китми алар. 19 ел буе имамсыз торган мәчетне үз өстенә алырга туры килә Искәндәр абыйга. Ул көннән соң 10 ел вакыт үтеп тә киткән инде.

Искәндәр абыйларның ишекләре тәүлекнең теләсә кайсы вакытында да ачык. Кайгы килсә дә, шатлык булса да, авыл халкы гына түгел, күрше авыллардан да киләләр аның янына. Агач эшен дә, тимер эшен дә яхшы белә ул. Олыны да, кечене дә хөрмәт итә. Хәтта авылга килеп чыккан хуҗасыз этләр дә аның янында тукталалар. Киң күңелле Искәндәр абый, кирәк икән, ярдәм итә, төпле киңәшен бирә. Аның олы йөрәгенә һәркемнең сере сыя. Кешеләрне сүз белән генә түгел, шәхси үрнәге белән тәрбияли.

Рәйсә РӘФЫЙКОВА.
Кама Тамагы районы Бәрлегуҗа авылы

УНИВЕРСАЛ

Россия ислам институтын тәмамлап, 2014 елны көзен Тимур Фәрит улы Латыйпов Шәле авылына «Заһир» мәчетенә имам булып кайта. Бу еллар эчендә күп нәрсә үзгәрә: балалар, кечкенә яшьтән дин белән кызыксынып, мәчеткә йөри башлыйлар, төрле түгәрәкләр ачыла, дингә игътибар арта. Барысы да нәрсәдән башлана?

Тимур хәзрәт Латыйпов Чабаксар шәһәрендә туа. Әтисе – ветеринария табибы, ә әнисе – пешекче. «Гади авыл гаиләсе – әти-әни, апа, мин һәм сеңел», – ди ул гаиләсе турында. Нәселләрендә Тобольск губерниясе мәчете мулласы да булган бит. Ул – хәзрәтнең карт бабасы.

1993 елда Тимур Фәрит улына 6 яшь булганда, алар гаиләсе белән әтисенең туган җиренә – Әгерҗе районы Тирсә авылына яшәргә кайталар. Татар телендә бары тик әтисе генә сөйләшә, шуңа беренче белемнәрне имам рус сыйныфында ала. Татар телен инде Тимур хәзрәт урамда өйрәнә. Күп нәрсә тарих укытучысы мәчеткә балалар җыя башлагач үзгәрә. Шул вакытта аңа дин кереп кала дип әйтергә була. Гаиләсендә бит укучы булмаган.

2003 елда хәзрәтнең тормышында «Россия ислам институты» дигән бүлек башлана. Ләкин ике ел укыганнан соң, дини югары уку йорты белән вакытлыча саубуллашып торырга туры килә. 2005 елда ул Казанның меңьеллыгыннан соң Чабаксар шәһәренә күчеп китә. Тимур Фәрит улы искә ала:

– Бабай әйтте: «Пешекчегә укырга кер – ач калмассың!» Бу сүзләрдән соң инде мин профессияне алыштырырга булдым. 2010 елга кадәр җәмәгать туклануы өлкәсенә бәйле идем. Әти үлгәч, минем тормышымда борылыш булды. Бик күп нәрсәгә карашым 180 градуска үзгәрде: эшкә, үземә, һөнәргә. Шулай мин РИУга (хәзер РИИ) яңадан укырга кердем. Дүрт ел эчендә булган чаралар әле дә күз алдында. 2013 елда инде диплом алгач, Мисырга гәрәп телен, тәҗвидне ныгытыр өчен китеп бардым. 2014 елда тәмамладым, шул ук елны көзен миңа Шәлегә имам булып кайтырга тәкъдим иттеләр.

«Заһир» мәчетеннән узып барганда, еш кына анда балалар җыелып торганны күрәсең. Кемдер мәчеткә керер алдыннан дустын көтә, кемдер ятлаган сүрәсен кабатлый, кемдер мәйданчыкта уйный. Шунысы дөрес: балалар бу җиргә тартыла. Сере нәрсәдә икән? Тимур хәзрәтнең үзеннән сорап карыйк әле.

– Бер бабай сөйләде: «Син килгәнче, урамда балалар дин ягыннан исәнләшә дә белмиләр иде, хәзер инде алар «Әссәламүгаләйкүм» дип әйтмичә китмиләр», – ди ул. Шәле халкы беренче шундый үзгәреш күрде. Икенче яңалык – авылда динне социаль челтәрләр аркылы тарата башладым. Бүген интернетта актив эшчәнлек алып барам. Барысы да пандемия вакытында башланып китте. Күп чикләмәләр күзәтелә башлагач, мин социаль челтәргә күчәргә кирәк дигән фикергә килдем. Мәчеттә балаларны җыеп, дәрес биреп булмаганлыкны аңлагач, интернет дөньясында эшчәнлек алып бару өчен кирәкле әйберләрне сатып алдым да дини белемнәрне онлайн бирергә булдым. YouTube каналында атнага 1–2 видеодәрес чыга. Хәзерге көндә 150дән артык видео җыелды, алар берничә категориягә бүленгән. Барысын да үзем төшерәм. Бу – беренче тәрбия ягы. Икенче ягы – игълан. Минем күзәтүләрем буенча, кызганычка, хәзерге яшьләрнең бик сирәге генә китап укый. Барысының да кулында телефон. Мәгълүматны күбесенчә аннан алалар, шуңа күрә безгә заманча технологияләрне өйрәнеп, алып барган барлык эшчәнлекне интернет челтәрләренә дә куеп барырга туры килә. Мин моны элек авыл башында торган кычкырып сөйләүче микрофон белән чагыштырам. Барлык кирәкле мәгълүматны авыл халык шуннан ишетә иде. Алга таба да планнар бик күп. Алар турында сөйләми торыйм инде әлегә. Шунысы бар: ярдәмчеләр һәм фикердәшләр кирәк. Әгәр алар булса, бик күп нәрсә эшләргә була. Без шуңа омтылабыз да.

Тимур хәзрәт Латыйпов бик күп укучылар чыгарды. Алар инде хәзер югары уку йортларында укыйлар. Төрле якларга таралсалар да, аларны бер нәрсә берләштерә – мәдрәсә. Резидә Бикчәнтәева – хәзрәт кайткан елны җыелган иң беренче төркем студентларының берсе. Ул укыган елларын ничек искә ала икән?

– Тимур хәзрәт безнең Шәле авылына 2014 елда кайтты. Ул вакытта әле мин яулык япмый идем, ләкин күңелем белән диндә, намазда идем. Дини белем алырга елларда йөрдек. Беренче көннәрдән үк сиздем – Тимур хәзрәт мәдрәсә тормышына зур яңалыклар кертте. Укудан тыш безгә мастер-класслар да оештырылды, төрле яктан үсүгә дә басым ясалды. Ул күп нәрсәгә безнең күзләрне ачты, дияргә була. Бәлки алар ярдәме белән мин яулык бәйли башлаганмындыр, Тимур хәзрәттә этәргеч күрәм. Уку программасы үзгәрешләр кичерде. Хәзрәт балаларга якынаю юлын таба белде, шуңа алар өчен уку тагын да кызыграк була башлады. Ә инде белем туплагач, ул безгә сюрпризлар оештыра иде. Шулай ул безне Казанга экскурсияләргә йөртте, конкурсларга әзерләде. Авыл баласына ничек күңелле иде бит! Бу безгә тагын да күбрәк белем алырга стимул кебек булган инде.

Тимур хәзрәт килгәннән соң авылда үзгәрешләр күренә: авылыбыз зиратын кара урман булып агачлар басып бетергән иде – һәр ел берничә тапкыр авыл халкын өмәгә җыеп, зиратны әкренләп тәртипкә китерәләр; «Заһир» мәчетендә дә эшләр кайный – балалар өчен дини чаралар уздыралар, мәдрәсәдә белем бирәләр. Шуның өстенә балалар өчен кышкы чаңгы ярышлары, җәйге мөселман Сабан туйлары да оештырырга өлгерә. Гаиләсе дә бар: хәләл җефете белән ике бала үстерәләр.

Безнең авыл имамы, бер сүз белән генә әйткәндә, универсал. Андыйларны табу бик авыр хәзерге заманда. Тик шулай да мине бер генә сорау борчый. Тәүлек буена ун кеше эшли алмаган эшләрне башкарып чыга, ә ул йоклап ял итәме икән?

Бер дә белмәгән авылга бер сумка белән кайткан кеше Шәледә дини үсешкә бик зур өлеш кертте. «Мин, авылга килгәндә, бернинди дә хезмәт хакы турында уйламаган идем. Аллаһ ташламас, эшләп карыйм дип кайттым», – дип искә ала хәзрәт. Хәзер инде Тимур Фәрит улы турында җылы сүз әйтмәгән Шәле кешесе калмагандыр. Без аңа бик рәхмәтле!

Ләйлә ХӘЙРУЛЛИНА

КОТЛЫЙБЫЗ!



Республиканың мөхтәрәм шәхесе
Марс Шәрип улы АЛИЕВка
18 июльдә 75 яшь тула.

Сокланырлык, мактаулы, үрнәк тормыш юлы үтә ул. Буа районының Иске Тинчәле авылында дөньяга аваз салган егет, ветеринария институтында зоотехник белгечлегенә ия булганнан соң, берничә ел тәҗрибә туплый, аннары Биектау районының «Биектау», «Калинин», «Кызыл байрак», «Урак һәм чүкеч» колхозларында җитәкчелек вазыйфасында була, Татарстан авыл хуҗалыгы министрының беренче урынбасары буларак та тармакны үстерүдә тәҗрибәсен бик үтемле файдалана. Шул елларда кандидатлык, докторлык диссертацияләрен яклый, профессор буларак институтта авыл хуҗалыгы өчен белемле яшьләр әзерли, үзе исә – йөздән артык фәнни хезмәт авторы, Россия Хөкүмәтенең фән һәм техника өлкәсендәге премиясенә лаек була. «Татптицепром»га җитәкчелек иткән чоры шулай ук бик үтемле һәм нәтиҗәле. Бүген дә ул – Татарстан агросәнәгате ветераннар советы рәисе.

Казан белән янәшәдәге Чабакса бистәсенең танымаслык булып үзгәрүендә дә Марс Шәриповичның өлеше ифрат зур. Заманында шушы бистәдә газчылар карамагындагы ярдәмче хуҗалык җитәкчесе буларак төзекләндерүдә армый-талмый хезмәт куйды. Әтисе – мөгаллим Шәриф истәлегенә төзелгән мәчет тә шушы бистәдә. Әле шушы көннәрдә генә мәчет янәшәсендә «Ислам дине үзәге» дә ачылды. 1930–1937 елларда ТАССР Халык комиссарлары советы рәисе булган авылдашы, туганы Кыяметдин Алимбек улы Абрамов истәлегенә ТАССР төзелүнең 100 еллыгын бәйрәм иткән көннәрдә мәчет салдыру да Марс Шәриповичның уй-нияте белән гамәлгә ашырылды.

Без аның янәшә-тирәдәгеләргә булган мөнәсәбәтенә, ярдәмчеллегенә гомер буе сокланабыз. Киләчәктә дә ниятләре гамәлгә ашып торсын, Аллаһы Тәгалә исәнлек-саулыктан, тигезлектән аермасын! Туган көнегез мөбарәк булсын, хөрмәтлебез!

Буа якташлык җәмгыяте.
Теләкләргә хәләл җефете Мөнирә, балалары, оныклары, якыннары, таныш-белешләре бик теләп кушыла.

Язучы фикере

Планка

Планка инде мин. Белмим, әдәби татар телендә минем асылымны билгели алырлык сүз бар микән… Тик барсы да «планка» дип йөртә – урысы да, татары да, чуашы да, марие да… Шуңа хәзер үзем дә күнектем. Планка һәм вәссәлам.

Менә сез биеклеккә сикерергә телисез икән, ике багана арасына мине куясыз. Метр ярымга, мәсәлән. Сикереп чыгасыз. Тагы мине күтәрәсез. Метр да алтмыш сантиметрга. Югарырак була. Мөмкинлегегез җитмәсә, сез мине тибеп очырасыз. Метр да алтмыш сантиметр – сезнең өчен югары биеклек. Сезгә метр да илле тугыз ярым сантиметр кирәк. Бер сантиметр яки бер миллиметр гына җитми калса да, сез мине тибеп очырасыз. Шул рәвешле мин типкелектә яшим. Үз гаебем буенча түгел, ә сезнең мөмкинлекләр чикле булганга.

Шуңа күрә сезнең уңышларга, сезнең мөмкинлекләргә иң нык сөенгән зат – мин, планка. Сезнең сәләт ни дәрәҗәдә югарырак була – мин шул дәрәҗәгә күтәреләм. Сез никадәр булдыксызрак – мин шулкадәр типкелектә яшим. Мин – сезнең планкагыз.

Мин бит инде – авыртуларны тоя белгән, уйлана белгән нәрсә. Әгәр синең аша сикереп чыгарга теләп тә булдыра алыйча кемдер сиңа җан ачуы белән, бөтен көче белән тибеп җибәрә икән, монда инде авыртуны тоймый булмый. Ә авырту, сызлану ул һәрвакыт уйлануга этәрә. Һич югы, бу халәттән ничек котылырга икән, дип уйлый башлыйсың. Мине элеп куя торган ике багана бар. Аларга беркем типми, беркем бәрелми. Бу тормышта матур урнашканнар. Аларны беркем бимазаламый. Утыралар шунда башларын күккә чөеп. Безнең чиновниклар кебек инде алар. Берни эшләмиләр, бернинди каза күрмиләр, берни өчен җавап бирмиләр. Һәм алар икәү. Ә мин – берәү генә. Берәү генә булганнарның тормышлары һәрчак авыр инде. Икәү булсаң әле бер-береңә сарылып еларга да була. Ә берәү генә булгач, елый алмыйсың – сине беркем дә аңламаячак, һәр җан иясе сине мескен дип уйлаячак. Әгәр күпчелек мескен дип уйлый икән, син чынлап та мескенлеккә төшәргә мөмкинсең. Шуңа күрә көчле булырга кирәк. Сине тибеп очыралар, ә син елмаясың. Балкыйсың… Юк, елмаерга да, балкырга да ярамый. Менә кемдер синең аша сикерергә тели, ә хәленнән килми, мине тибеп очыра – ә мин елмаям. Ну, ярамый алай. Чөнки минем елмаюым аның мескенлегеннән көлү булып тоелачак. Һәм ул мине тагын әллә кайларга болгап очырырга мөмкин. Алла сакласын. Шуңа күрә миңа еларга да, елмаерга да ярамый. Елавымны күрсәләр, мескенгә санаячаклар, ә елмаюым мәсхәрәләү булып тоелачак. Тыныч булырга кирәк.

Ә тыныч булып булмый. Әле бит адәм баласының төрлесе бар. Кемдер синең аша сикереп чыгарга тели дә булдыра алмый, һәм ул гаепне үзеннән эзләми, сине гаепли һәм тибеп очырган җиреннән эзләп табып, аяклары белән изәргә тотына, җиргә сеңдерергә тырыша. Җиргә сеңгәч, планка аның аяк астында булып тоела бит инде. Аңа рәхәт була торгандыр. Ә сиңа кыен. Чөнки син кешеләрне яратасың. Дөньяның иң авыр җәрәхәте ул – яраткан затларыңның мескенлеге.

Ә мин зыянлы да, гаепле дә зат түгел. Мин – бары тик планка гына. Мин – сезнең кемлегегезне күрсәтеп торучы. Бу да зур бәхет түгел. Юк, мөмкинлекләре югары булган кешеләрне дәртләндереп тору – бәхет. Ләкин бераз түбәнрәкләр дә бар бит. Алар күп. Әгәр син күпчелекнең кемлеген күрсәтергә телисең икән, дөньяда иң мәхәббәтсез затка әйләнәсең. Үзенең мескенлеген беркем дә күрергә теләми. Һәркем үзен искиткеч мөмкинлекләргә ия булган бердәнбер һәм кабатланмас зат итеп тоярга тели. Ә син аларны шушы теләгеннән мәхрүм итәсең. Шундый затны кем яратсын инде?

Мин – планка. Уңайлы зат булмасам да, файдалы зат. Ә файдалылар – һәрвакыт эт типкесендә. Типкелектә яшәсәм дә, мин сезне гафу итәм. Яратам мин сезне. Ә ярату барсын да кичерә ала. Сез дә мине артык гаепләмәгез, яме. Мөмкинлекләрегез минем югарылыкка җитеп бетми икән, гафу итегез. Үз теләгем белән генә түгел бит инде бу, Ходай мине шулай яралткан. Мин һәрвакыт югары булырга тиеш. Бу дөньяда минем вазыйфам шул.

Сез дә – минем планкам. Сез ни дәрәҗәдә камилрәк булсагыз, мин шул кимәлдә югарырак булачакмын. Сезнең уңышларыгыздан балкый-балкый, мин дә югарырак менәчәкмен. Һәркем камиллеккә омтылырга тиеш. Шул вакытта типкәләү һәм типкәләнү бетәр. Югарырак күтәрегез үзегезне һәм сикерегез!

Мин сезгә югарылык, биеклек һәм бөеклек телим. Мин – планка.

Марат КӘБИРОВ

КАЙГЫ УРТАКЛАШУ

«Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре советы» ассоциациясе,

әтисе

кинәт вафат булу сәбәпле, Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесе Беляев Радмир Илдар улының авыр кайгысын уртаклаша.

Мин кулыма китап алам…

ГАЗИНУР МОРАТ:

«ХАЛКЫ НИНДИ – ЯЗУЧЫСЫ ДА ШУНДЫЙ»

Басма матбугат, әдәбият ни хәлдә? Кулына чын китап, газета яисә журнал тотып укучыларның санын ничек арттырырга? Уку культы кире кайтырмы? Әдәбиятны ничек җанландырырга? Бу һәм башка сорауларга җавапны Г. Тукай премиясе иясе, шагыйрь һәм публицист Газинур МОРАТ белән эзләдек.

:: Бүгенге басма матбугат, әдәбиятның хәленә нинди бәя бирәсез, Газинур абый?

– Без үскәндә, матбугатның абруе бик зур иде. Әти белән әни, гади колхозчылар булсалар да, газета-журналларның төрлесен алдыртты. Без дә, уеннан, өйдәге эшләрдән арынган чакта, укырга тырыштык. Төп юанычыбыз да, шөгылебез дә китап һәм газета-журналлар булды. Уку культы бар иде ул вакытта. Тормышыбызга өермә кебек социаль челтәрләр, интернет килеп кереп, басма матбугатның да, әдәбиятның да тез астына сукты. Заманында телевидение дә ул кадәр үк тәэсир итмәгән иде. Кайчак миңа кулга чын китап, газета яисә журнал тотып уку ниндидер борынгы шөгыльгә әйләнеп бара кебек тоела.

Уку – зур хезмәт бит ул. Тырышлык, ихтыяр көче сорый, уйлата торган хезмәт. Ә кулда телефон, каршыда компьютер булганда, уйлап торасы юк, коры мәгълүмат кына аласың. Алгарыш ул кешене ялкаулыкка өйрәтә. Алга таба барабыз дип, артка чигендек. Прогрессның нигезендә ялкаулык ята. Кеше, азрак селкенер өчен, һаман саен нәрсәне дә булса камилләштерергә омтыла. Ләкин адәм баласы укудан йөз чөермәскә тиеш. Мин бу хәлләрне вакытлыча дип уйлыйм. Һәрхәлдә, цивиль дөнья һәрнәрсәгә ихтыяҗны тигез бүлә дип беләм.

:: Алай да, бөтенләебез белән интернетка күчеп беттек, дию дөрес булмастыр.

– Әлбәттә. Укыган кеше укый инде ул. Кулына китап тотып үскәннәрне укудан алай гына аерып булмый. Менә шушы интернет заманында туган буын кулына китап алырга өйрәнерме? Бусы бераз шикләндерә.

:: Уку культын кабат кайтарып булырмы икән?

– Заманында язучылар, тәнкыйтьчеләр, чын әдәбият мондый булмый, дип, Габдрахман Әпсәләмовның әсәрләрен шактый тәнкыйтьләгән. Шунда Хәсән Туфан: «Без аңа рәхмәтле булырга тиеш. Татар язучыларының сафы нык сирәгәйгән бер вакытта татар укучысын китаптан аерырга ирек бирмәде, китапка мәхәббәт саклый алды», – дигән. Бүген халыкка «Укыгыз!» дип кенә уку культын кире кайтарып булмый. Бу мәсьәлә барыбер укучы игътибарын җәлеп итәрлек әсәрләр иҗат итүгә кайтып кала дип уйлыйм мин. Әллә нинди гениаль әсәр язылып та, укучы аңа игътибар итмәскә мөмкин. Ә чын әдәбияттан ерак торган әсәрләрне, киресенчә, егылып укырга мөмкиннәр. Әйтик, «Татмедиа» «Казан утлары» белән берлектә кесә китаплары чыгара башлады. Сыйфат ягыннан төрле әсәрләр бастыра алар да. Һәм ул китаплар сатылып бетә, диләр.

Гомумән, җитди әдәбият белән укучы кызыксынып укый торган әсәрләрне каршы куярга ярамый. Алар – икесе ике нәрсә. Ләкин халыкны әдәбияттан, ана теленнән аермау өчен, әнә шул җиңел укылышлы әсәрләр дә булырга тиештер.

:: Безнең әдәбиятка нинди жанр җитми?

– Бездә детектив – бик дефицит жанр. Хатын-кызлар егылып укый торган мәхәббәт маҗаралары турындагы әсәрләргә бирешмәслек, бик үтемле жанр ул үзе. Кызыклы итеп язылса, билгеле. Мавыктыргыч детектив әсәрләр дә халыкны китапка якынайтуның үтемле чарасы булып тора.

:: Газинур абый, бүген татарча китапларның бәясе дә бар бит…

– Бу – безнең иң авырткан җиребез инде. Аның һәм объектив, һәм субъектив сәбәпләре бар. Соңгысы турында хәзергә әйтмичә торам. Бүген бәясе артмаган нәрсә калмады кебек. Шул исәптән, китап чыгару да кыйммәтләнде. Аннан соң хәзер тиражлар да аз бит. Бәягә бу да йогынты ясый. Мондый шартларда кешенең күңелен түгел, тамагын кайгыртуы – табигый хәл. Гомумән, әлеге мәсьәлә барлык язучы халкын борчыйдыр. Бу турыда, һичшиксез, уртага салып сөйләшергә кирәктер.

:: Китап кибетләрендә балалар өчен басмалар бик күп күренә. Белүемчә, яхшы сатыла да алар. Ә үсмерләргә нәрсә укытыйк икән?

– Үсмерләргә атап иҗат итүчеләр элек тә берән-сәрән генә иде, хәзер дә шулай. Әйтик, узган ел Марат Әхмәтов җитәкли торган комиссия химаясендә зур әдәби бәйге булды. Аңа җәмгысы 1470 әсәр килде. Шуның 15е – роман. Ләкин анда да үсмерләр өчен язылганнары бик сирәк очрады. Ни өчен алай икәнен үзем дә аңлап бетерә алмыйм.

:: Язучыларның хәле турында да сөйләшик әле.

– Тагын үткәннәрне искә алмыйча булмый инде. Чөнки элек язучы һөнәренең абруе искиткеч югары иде. Шуны күреп, шуңа ышанып яза башлаган кешеләр инде без дә.

Ничек кенә булмасын, язучы зарланырга тиеш түгел дип беләм мин. Бер классик әйтмешли, минем бәхетле булырга хакым юк, чөнки мин – язучы. Халык хадиме ул язучылар, аның бәгыреннән өзелеп төшкән җаннар. Халкы нинди – язучысы да шундый була инде.

:: Сез телгә алган бәйгенең әҗере дә саллы иде. Гомумән, мондый чаралар язучыларны, әдәбиятны җанландырамы?

– Әлбәттә. Язучылар өчен мотивация әнә нинди көчле булды бит. Ул бәйгегә шундый яхшы поэмалар, повесть-романнар, хикәяләр килде. Гаҗәп инде, бер караганда. Язучыларны җанландыру гына түгел, укучының да шулай югары бәяләнгән әсәрләрне укыйсы килә бит. Менә әкренләп шулардан җыентык туплап, бастырырга ниятлибез. Гомумән, әдәби процесста мондый чараларның роле гаять зур. Шуңа күрә бәйгеләр булып торырга тиеш.

«Татар-информ»

Газинур Морат фикеренчә, һәр татар укырга тиешле 5 китап:

1) Мөхәммәт Мәһдиев «Торналар төшкән җирдә»;
2) Әмирхан Еники «Әйтелмәгән васыять»;
3) Хәсән Сәрьян «Бер ананың биш улы»;
4) Марсель Галиев «Рух»;
5) Аяз Гыйләҗев «Җомга көн кич белән».

:: Сезнең өчен китап – нәрсә ул, Газинур абый?

– Дөньяда китаптан да зуррак, мәгънәлерәк тагы нәрсә бар икән инде? Тормышымның мәгънәсе ул китап. Халыклардан да, цивилизацияләрдән дә китаптан башка берни дә калмый. Дөньяны үзгәрткән ачышлар да фәкать китап булганга гына ясалган. Билгеле, Җир йөзендәге барлык китаплар укырга лаек та түгелдер. Ләкин дөнья әдәбиятында да, безнең әдәбиятта да укырга лаеклары бихисап.

:: Соңгы укыган китабыгыз нинди?

– Ринат Мөхәммәдиевнең кесә китабы итеп чыгарылган «Кыргый атауга сәяхәт»ен укыдым.

Әңгәмәдәш – Лилия ГЫЙМАЗОВА

ЕРАГАЙМАСЫН АРА

Илдар Мөхәммәтҗанов

Әдәби әсәр белән китап сөючеләр арасындагы элемтә ни хәлдә? Бүген татар китабы үз укучысына барып җитәме? Бу юлда нинди киртәләр бар? Әлеге сорауларны язучыларның үзләренә бирдек.

Нәбирә ГЫЙМАТДИНОВА:

– Китап сөючеләр белән язучылар арасындагы элемтәне элек-электән китапханәчеләр, укытучылар җылытып торды. Китапханәләрдә, мәктәпләрдә очрашулар уздырып, укучы белән күзгә-күз аралашу бик үтемле чара иде. Бүген дә укучы белән язучы арасына күперне менә шул рәвешле дә салып була дип уйлыйм. Заманында, татар теленең куәтле чорында очрашуларны бик күп уздырдым. Аеруча мәктәпләргә еш йөри идем. Балалар сорау өстенә сорау бирә, бәхәсләшә, кызыксына. Сөйләргә гел ирек бирмиләр. Билгеле, хәзер хәлләр башкачарак. Кайсы гына мәктәпкә барып керсәң дә, балалар бик аз укый. Очрашасың, үзең сөйлисең дә китәсең.

Әсәр белән укучы арасындагы элемтәне якынайта торган тагын бер чара итеп Раил Гатауллин («Татнетны үстерү фонды» җитәкчесе) тәҗрибәсен атар идем. «Әдәби марафон»да катнашучылар гаять күп бит. Араларында мәктәп укучылары да елдан-ел арта. Кайбер татар теле укытучыларының балалар белән эшләве нәтиҗәсе инде бу. Гомумән, балаларга китапка карата мәхәббәт уятуда аларның роле бик зур бит.

Бүген татар китабын күбесенчә 50–55 яшьлекләр укый. Һәм шунда ук сорау туа. Ә аларга алмаш булырмы соң? Әдәби бәйгеләр уза, аларга меңәрләгән әсәр килә. Араларында яхшылары, бик яхшылары бар. Тик аларның меңәрләгән укучысы бармы икән? Билгесез.

Лилия ГЫЙБАДУЛЛИНА:

– Беренче чиратта, әдәби әсәр белән укучы арасындагы киртәләр укучының кайсы буын вәкиле булуына карый. Бездә һәм безгә кадәрге буында китап культурасы бар. Без – нәшриятта басылган китапларны барлап, көтеп, укып яши торган буын. Ә яшьрәкләргә электрон китаплар, аудио форматындагы әсәрләр кызыклырак, миңа калса. Кайвакыт үзем дә кулда булмаган китапны интернет аша эзләп карыйм, таба алмыйм. Татар китапларын онлайн сатып алу, уку катлаулырак әлегә. Алай да, әкренләп Ozon, Wildberries ише мәйданчыкларга чыга башладылар кебек. Заман биргән мөмкинлекләрдән активрак файдалансак иде. Кулларыннан телефон төшмәгән буынга милли форматтагы уеннар, уен форматына күчерелгән әсәрләр кирәк. Билгеле, җиңел генә хәл ителә торган мәсьәлә түгел бу, тулы бер команда хезмәте таләп ителә. Ләкин киләчәктә кулына китап алып, әдәби әсәр укый алырлык буын тәрбияләргә телибез икән, безгә һич югы шушы мөмкинлекләрне кулдан ычкындырмаска кирәк.

Ә инде укучы белән китап арасындагы төп киртәләр, ахыр чиктә, тел, милли мәгариф проблемасына барып тоташа. Әдәби әсәр барып җитсен өчен, укучыда әдәби зәвык булырга тиеш. Ә ул китап укып үскән буында гына була ала. Безнең мәктәпләрдәге ике-өч сәгать татар теле дәресе белән зәвыклы укучы тәрбияләү мөмкин эш түгел.

Рүзәл МӨХӘММӘТШИН:

– Рус язучысы Сергей Довлатов җитмешенче елларда чыккан бер әсәрендә Америка белән иң күп укый торган ил дигән даны таралган Советлар Союзын чагыштыра. Үзенең Кушма Штатларда гомер иткән чагы. «Әлбәттә, Советлар Союзында укыйлар, анда бит башка күңел ачу чарасы юк, кешенең бердәнбер юаныч һәм куанычы – китап. Ә монда вакыт уздыру, кәеф-сафа кору өчен чаралар җитәрлек. Ә бөтенесен «авыз итәргә» теләгәч, китапка ихтыяҗ кими», – ди Довлатов. Бүген бездә дә андый чаралар җитәрлек. Китап укучы юк, дигән фикер белән килешмим. Кешенең башка мавыгулары арту бәрабәренә бу сан кимеде генә.

Ә менә яңа чыккан китап турында аны укырга теләүченең хәбәрдар булу-булмавы – икенче мәсьәлә. Әсәрнең потенциаль укучысына китап, аның авторы турындагы мәгълүмат барып җитсә, бу вазгыять бераз хәрәкәткә килер иде. Бу җәһәттән Язучылар берлеге янында элеккеге «Бюро пропаганды» сыманрак матур әдәбиятны популярлаштыру бүлеге булдыру яхшы булмасмы икән? Районнарга, мәктәпләргә чыгып, очрашулар уздыру ярдәм итәр кебек. Бу эшне язучының үзенә генә дә калдырасы килми бит. Үзе продюсер да булган язучы болай да йөри ул.

Баш мөхәррир – САБИРОВА Гөлнара Ильяс кызы

Газетаны оештыручылар:
ТАТАРСТАН ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ, МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ, РЕДАКЦИЯНЕҢ ХЕЗМӘТ КОЛЛЕКТИВЫ

Газета Татарстан Республикасы Информация һәм матбугат министрлыгында 1995 елның 21 июнендә теркәлгән.

Теркәү таныклыгының номеры – 430.
Газета матбугат чараларының үзәк каталогына кертелгән.

Тираж – 6640 данә
Гомуми тираж – 16052 данә

Газетага сертификат бирелде Заказ 299

РЕДАКЦИЯ ҺӘМ НӘШЕР АДРЕСЫ

420097, Казан, Академия ур., 2 й.
«Ватаным Татарстан» газетасы редакциясе.

www.vatantat.ru

info@vatantat.ru, vatantat@list.ru, vtreklama@mail.ru

89179270040

Индекс П2409 (гадәти сан – атнага дүрт тапкыр чыга)
П2448 (гадәти сан, пенсионерлар өчен)
П2449 (гадәти сан, оешмалар өчен)
П2435 (җомга саны)

ТЕЛЕФОННАР

222-09-70 – кабул итү бүлмәсе
222-09-67 – баш мөхәррирнең беренче урынбасары
222-09-73, 222-09-69, 222-09-65 – баш мөхәррир урынбасарлары
222-09-68 – авыл хуҗалыгы, фән һәм мәгариф
222-09-67 – дин, сәламәтлек
222-09-64 – әдәбият, сайт
222-09-66 – сәясәт, тәрҗемә, оператор, хатлар һәм социаль мәсьәләләр
222-09-65 – реклама бүлеге
222-09-72 – бухгалтерия
222-09-73 – компьютер үзәге
221-18-99 – газета килмәсә яки соңарып килсә

Оригинал макет **Jahat™** программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде. Мәкалә авторларының фикерләре редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин. Хатлар, кульязмалар, рәсемнәр рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
R тамгасы куелган язмалар реклама буларак тәкъдим ителә.
N тамгасы куелган язмалар килешү нигезендә басыла.

Күчереп бастыру өчен редакциядән язмача рөхсәт алу шарт.
График буенча бу санга 20 сәгатьтә кул куелырга тиеш.
Кул куелды – 20 сәгатьтә.

Ваклап сату бәясе килешү буенча.

Газета «ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылып чыкты **(420066, Казан шәһәре, Декабристлар ур., 2й.).**

16+